ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» декабрь 2025 ел № 345

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү муниципаль программасын раслау турында»гы 2023 елның 6 апрелендә кабул ителшән № 77 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5мартында кабул ителгән «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү дәүләт программасын раслау турында"гы 159 нчы номерлы карары карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 ноябрендә 3081-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган "2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясендә физик культураны һәм спортны үстерү стратегиясен раслау турында»гы нигезендә, Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү максатларында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 6 апрелендә 77нче номерлы карары белән расланган «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Программа паспорты. Программаны финанслау чыганаклары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## Программа паспорты

| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары күләмнәре: | Программаны Әгерҗе муниципаль районы бюджетыннан финанслауның гомуми күләме: | | |
|---|---|---|---|
| | ел | Җирле бюджет | Республика бюджеты |
| | 2023 ел | 199,8 мең сум | 128,12 мең сум (спорт инвентаре);<br>399,0 мең сум (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга) |
| | 2024 ел | 199,8 мең сум | 115,78 мең сум (спорт инвентаре);<br>377,8 мең сум. (хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга ) |
| | 2025 ел | 199,8 мең сум | 246,15 мең сум (спорт инвентаре);<br>470,7 мең сум(хоккей буенча программаларны гамәлгә ашыруга)<br>40,0 мең сум(хезмәткәрләргә-яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга)<br>130,0 мең сум югары квалификацияле спортчыларны әзерләгән өчен тренер-укытучыларга, шулай ук спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче спортчы – инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алган нәтиҗәләре өчен түләүгә |
| | Барысы | 599,4 мең сум | 1 907,55 мең сум |

1.2. 6нчы бүлек. 2023-2025 елларга Әгерҗе муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү чаралары. 5.6 пунктлар. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| № | Чараларның эчтәлеге | Үтәлү вакыты | Җаваплы | Финансирование күләме (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **2023** | **2024** | **2025** |
| 5.6 | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты | 2023-2025еллар | ТР Әгерҗе | 128,12 | 115,78 | 246,15 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | карары нигезендә спорт җиһазлары, экипировка һәм спорт мәктәпләрен җиһазлау өчен инвентарь алуга бюджетара трансфертлар. (республика бюджеты) | | муниципаль районы муниципаль казна өстәмә белем бирү учреждениесе “Спорт мәктәбе” | | | |

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына федераль бюджет кысаларында «Физик культура һәм спорт» юнәлешендә каралган муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруга бюджет акчалары бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
2. Әлеге карарны Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. Н. Бәдәхшинга йөкләргә.

**Җитәкче** **И.Х. Салихов**